КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 апрель г.Казань № 289

2019 елга Халык өстенлекләре
реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасының норматив хокук актларын һәм муниципаль хокук актларын кабул иткәндә һәм тормышка ашырганда җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны оештыру тәртибе турында» 2007 ел, 19 март, 90 нчы карарын үтәү йөзеннән һәм 2018 елда үткәрелгән социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елга Халык өстенлекләре реестрын (алга таба – Реестр) расларга.
2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча чараларны Татарстан Республикасының гамәлдәге һәм эшләнелүче дәүләт программаларына кертүне тәэмин итәргә, шулай ук әлеге чараларны тормышка ашыруны мониторинглауны контрольдә тоту буенча җаваплы затларны боерык белән билгеләргә.
3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнары белән бергә Реестрда күрсәтелгән халык өстенлекләрен тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эше барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктыртуны тәэмин итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 15 апрель, 289 нчы
карары белән расланды

2019 елга Халык өстенлекләре реестры

| Т/с | Өстенлек исеме | Өстенлекне билгеләгән халык өлеше, процент | Социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча формалаштырылган төп проблемалар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Бәяләр һәм тарифлар үсүне тыеп тору, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын күтәрү | 57,2 | бәяләр һәм тарифлар үсү;<br>бәяләр һәм тарифларның икътисадый нигезсез булуы;<br>товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләренең аларның сыйфатына туры килмәве;<br>гомуми йорт ихтыяҗларына торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә өстәп исәпләүләрнең югары булуы;<br>торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүләр формалаштыруның ачык булмавы;<br>торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре эшчәнлегенә дәүләт тарафыннан контроль булмау |
| 2. | Халыкның керемнәре дәрәҗәсен күтәрү (эш хакларын, пенсияләрне, пособиеләрне) | 49,1 | эш хакларының, пенсияләр һәм пособиеләрнең түбән дәрәҗәсе;<br>халык керемнәрен диспропорциональ бүлү |
| 3. | Ришвәтчелек һәм коррупциягә каршы тору | 36,2 | хакимият органнарында коррупцияне кисәтү буенча эшнең җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмавы;<br>гражданнарның түбән хокукый культурасы;<br>хокук саклау органнарына ышанычның түбән булуы; |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
| --- | --- | --- | --- |
| | | | ришвәтчелеккә җәза бирү системасының тиешле дәрәҗәдә каты булмавы |
| 4. | Эшсезлек дәрәҗәсен киметү | 29,5 | югары хак түләнә торган эш урыннарының җитәрлек санда булмавы;<br>җитештерү үсеш алмау;<br>кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә хакимият органнарының игътибары җитмәү |
| 5. | Торакның һәркем алырлык булуын тәэмин итү | 24,4 | урта һәм түбән керемле гаиләләр өчен торак сатып алуны күздә тоткан программалар санының җитәрлек булмавы;<br>үсеш алмаган дәүләт торак төзелеше;<br>ипотека кредиты буенча югары процент ставкалары |
| 6. | Әйләнә-тирә мохит торышын яхшырту | 23,6 | гражданнарның түбән экологик культурасы<br>юлларда автомобильләр саны арту, аларның йортлар ишек алларында туплануы;<br>агым суларны сыйфатсыз чистарту;<br>предприятиеләрнең атмосфера һәм суга зарарлы калдыклар чыгаруы;<br>шәһәр (поселок) территориясендә экологик зарарлы җитештерүләр булу;<br>урамнарда чүп савытларының җитәрлек булмавы;<br>урамнарда чүпне сыйфатлы җыймау |
| 7. | Наркоманлыкка һәм эчкечелеккә каршы тору | 23,2 | эчкечелек һәм наркоманиядән мәҗбүри дәвалау системасының булмавы;<br>алкогольле продукцияне куллануның чамадан тыш булуы һәм түбән культурасы |